ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 446-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары К.Ә. Ногаев һәм Ф.В. Вәлиев тарафыннан кертелгән «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 446-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 13 июле
№ 2045-VI ДС

Проект

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 9 пунктына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталы (PRAVO.TATARSTAN.RU), 2023 елның 21 июне), «2024 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2027 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты белән инновацион проектларны гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе яисә Татарстан Республикасы хөкүмәтләре карарлары нигезендә булдырылган технопарклар (индустриаль парклар), инновацион-технологик үзәкләр өчен түләп вакытлыча хуҗа булуга һәм файдалануга яисә вакытлыча файдалануга бирү өчен каралган мөлкәткә карата исәпләнгән салым суммасыннан 22,73% күләмендә салым түләү рәвешендәге оешмалар мөлкәтенә салым ташламасының гамәлдә булуын 2027 елның 1 гыйнварына кадәр озайтырга тәкъдим ителә.

Бу дәүләт ярдәме чарасы әлеге мәйданчыкларга (технопаркларга, индустриаль паркларга, инновацион-технологик үзәкләргә) аренданың ташламалы шартларында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына биналар бирү мөмкинлеге тудыра һәм аларны инновацион эшчәнлек өлкәсенә җәлеп итүгә ярдәм итә.

Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе мәгълүматына караганда, 2020 елда ташламадан 9 салым түләүче файдаланган, ташлама суммасы – 237,2 млн сум; 2021 елда ташламадан 10 салым түләүче файдаланган, ташлама суммасы – 239,3 млн сум; якынча мәгълүмат буенча 2022 елда ташлама суммасы 300 млн сум тәшкил итте.

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә башкаларын кабул итүне таләп итми.

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

Инновацион проектларны гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе яисә Татарстан Республикасы хөкүмәтләре карарлары нигезендә булдырылган технопарклар (индустриаль парклар), инновацияле-технологик үзәкләр өчен түләп вакытлыча хуҗа булуга һәм файдалануга яисә вакытлыча файдалануга бирү өчен каралган мөлкәткә карата салым ташламасының суммасы бер елга 368,7 млн сум күләмендә бәяләнә.

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Законы проектына**

**ЧАГЫШТЫРМА ТАБЛИЦА**

| Татарстан Республикасы Законының гамәлдәге редакциясе | Тәкъдим ителә торган үзгәреш | Татарстан Республикасы Законының тәкъдим ителә торган үзгәрешне исәпкә алган редакциясе |
|---|---|---|
| 5 статья. **Аерым салым ташламаларының гамәлдә булу сроклары**<br><br>Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:<br>…<br><br>9) <u>2024 елның 1 гыйнварыннан</u> әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 15 пунктын, $2^1$ өлешенең 2 пунктын.<br>… | 5 статьясындагы 9 пунктында «2024 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2027 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырырга. | 5 статья. **Аерым салым ташламаларының гамәлдә булу сроклары**<br><br>Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:<br>…<br><br>9) <u>2027 елның 1 гыйнварыннан</u> әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 15 пунктын, $2^1$ өлешенең 2 пунктын.<br>… |